**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Зәй-Каратай авыл җирлегенең**
**Зәй-Каратай торак пункты гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2024 елның 1 апреле

№ 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратайавыл җирлегенең Зәй-Каратай торак пунктында гражданнар Җыенының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлегенең Зәй-Каратай торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, 2024 елның 1 апрелендәге «Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлегенең Зәй-Каратай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карары һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлегенең Зәй-Каратай торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү турында 2024 елның 1 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлегенең Зәй-Каратай торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зәй-Каратай авыл җирлегенең Зәй-Каратайторак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы һәм «Зәй-Каратай авыл җирлегенең Зәй-Каратай торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (җәй көне кул белән үлән чабу (килешү буенча түләү) Зәй-Каратай торак пунктында; балалар мәйданчыгы территориясендә койма урнаштыру Зәй-Каратай торак пунктында);

2) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Зәй-Каратай торак пунктында суүткәргечләр өзеклеген булдырмау; Зәй-Каратай торак пунктында су насосында һәм резервуарда ремонт эшләре );

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Вахит урамы, Дунай урамы, Яшьләр урамы, Озерная урамы, Пионер урамы, Подгорная урамы, Совет урамы буенча Зәй-Каратай торак пунктында юлларны кардан чистарту; Уңыш урамы, Якуп урамы; Зәй-

Каратай торак пунктында Пионер, Якуп урамнары буйлап вак таш белән каплау җайланмасы)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зәй-Каратай авылы, Совет урамы, 99 йорт, 1 бит; Үзбәк авылы, Луговая урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы М.И.Идиятова